**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

“06” октябрь 2023 ел Бикләң авылы №3

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бикләң авыл җирлегенең Бикләң авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Бикләң авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 ст. нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Бикләң авыл җирлегенең Бикләң авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 19 нчы октябре 13.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Тукай муниципаль районы Бикләң авыл җирлегенең Бикләң авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2023 елның 20 нче октябре 13.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслаrга:

“Бикләң авыл җирлегенең Бикләң авылы территориясендә 2024 елда балигъ булган, Бикләң авыл җирлегенең Бикләң авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләргә:
- масса-күләм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт инвентарьлары сатып алу;
- халыкның мәдәни ялын оештыру (халыкның үзешчән сәнгатьтә катнашуы өчен музыкаль аппаратура һәм сәхнә костюмнары сатып алу);
- Бикләң авылы эчендәге юлларны, китереп бирү ысулы белән,вак таш (щебень) сатып алып,төзекләндерү;
- Бикләң авылы урам яктылыгы өчен энергия саклаучы яктырткычлар һәм электр товарлары сатып алу;
- сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар хөрмәтенә архитектура-скульптура корылмасы элементларын сатып алу.

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

4. Тукай муниципаль районы Бикләң авыл җирлегенең Бикләң авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Тукай районы Бикләң авылы Чкалов урамы, 20А адресы буенча үткәрергә.

5. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Тукай районы Биклән авылы Ахметшина урамы, 69А адресы буенча үткәрергә.

6. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Биклән авыл җирлеге Башлыгы М.Ш.Сәхбеев